КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 19 март г.Казань № 236

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгамәлә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 июнь, 502 нче, 2022 ел, 11 март, 217 нче, 2022 ел, 9 август, 780 нче, 2022 ел, 6 декабрь, 1292 нче, 2023 ел, 9 июнь, 705 нче, 2024 ел, 7 май, 305 нче, 2024 ел, 30 декабрь, 1279 нчы, 2025 ел, 14 июль, 513 нче, 2026 ел, 9 февраль, 85 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгамәлә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мотивацияләнмәгән агрессия чагылышын билгеләү.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.11 пункт өстәргә:

«$3.1^{1}$. Хуҗасыз хайваннарга мотивацияләнмәгән агрессия күрсәтү турында карарны (алга таба - карар) хайваннар өчен приютның өч хезмәткәреннән торган комиссия кабул итә. Карар ирекле формада бәяләмә язу юлы белән рәсмиләштерелә.»;

3.30 пунктта «хайваннар өчен приют» сүзләреннән соң «яисә хайваннарны вакытлыча тоту пункты» сүзләрен өстәргә;

5.1 пунктта «Хуҗасыз хайваннарда мотивацияләнмәгән агрессия булу яисә булмау турында карар (алга таба - карар) хайваннар өчен приютның җитәкчесеннән һәм ике хезмәткәреннән торган комиссия тарафыннан кабул ителә. Комиссия карары ветеринария бәяләмәсен ирекле рәвештә төзү юлы белән рәсмиләштерелә.» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтага «Хайваннар өчен приютыннан» сүзләреннән соң «/хайваннарны вакытлыча тоту пунктыннан (кирәклесенең астына сызарга)» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 922 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1317 нче, 2023 ел, 2 сентябрь, 1061 нче, 2024 ел, 9 ноябрь, 974 нче, 2025 ел, 28 август, 641 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның беренче абзацына «хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген гамәлгә ашыру,» сүзләреннән соң «хайваннарны вакытлыча тоту пунктлары эшчәнлеген гамәлгә ашыру,» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның таблицасында:

түбәндәге эчтәлекле 31 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «$3^1$. | Хуҗасыз хайваннарны вакытлыча тоту пунктларында хуҗасыз хайваннарны вакытлыча урнаштыру һәм тоту (оешма штатында ветеринария табибыннан башка) | 8»; |

түбәндәге эчтәлекле 41 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «$4^1$. | Йорт хайваннарын вакытлыча тоту пунктларында хуҗасыз хайваннарны вакытлыча урнаштыру һәм тоту (оешма штатында ветеринария табибыннан башка) | 7»; |

түбәндәге эчтәлекле 51 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «$5^1$. | Хуҗасыз хайваннарны вакытлыча тоту пунктларында хуҗасыз хайваннарны вакытлыча урнаштыру һәм тоту (оешма штатында ветеринария табибы белән) | 6»; |

түбәндәге эчтәлекле 61 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «$6^1$. | Йорт хайваннарын вакытлыча тоту пунктларында хуҗасыз хайваннарны вакытлыча урнаштыру һәм тоту (оешма штатында ветеринария табибы белән) | 5». |

3. Бу карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин